ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 6 мае**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1180**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 2016/2017 елның кышкы шартларында торак-коммуналь хуҗалык, социаль-мәдәни өлкә объектларын эксплуатацияләүгә әзерләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында” Россия Федерациясенең Федераль закон, 2006 елның 17 мартындагы 21-ТРЗ номерлы “Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законы нигезендә, торак-коммуналь хуҗалык һәм социаль өлкә оешмаларын 2016/2017 елгы җылылык чорында тотрыклы һәм ышанычлы эшләве, вакытында һәм сыйфатлы әзерләү, кышкы шартларда эксплуатацияләгәндә өзлексез һәм куркынычсыз җылылык, су-, энергия белән тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь, җылылык-энергетика хуҗалыгы объектларын, социаль өлкә объектларын 2016/2017 елгы ягу чорына әзерләү чаралары планын расларга (1 нче кушымта).
2. Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь, җылылык-энергетика хуҗалыгы объектларын, социаль өлкә объектларын 2016/2017 елгы ягу чорына әзерләү эшләрен башкаруны оештыру, координацияләү һәм контрольдә тоту буенча штаб төзергә һәм аның составын расларга (2 нче кушымта).
3. Зеленодольск муниципаль районының предприятие, оешма һәм учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:
   - торак-коммуналь, җылылык-энергетика хуҗалыгы объектларын һәм социаль өлкә объектларын әзерләү буенча чаралар планын үтәүне 2016 елның 15 августына кадәр тәэмин итәргә,
   - атна саен, 2016 елның 15 июненнән башлап, «ТР ЗМР ТКХ департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә ягулык чорына әзерлек буенча чаралар планын үтәү барышы турында мәгълүмат бирергә,

- торак-коммуналь хуҗалык объектларының әзерлек паспортын 2016 елның 15 августына кадәр расларга.
- 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы "Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" гамәлдәге Федераль закон нигезендә, ягу сезонына әзерләнү чорында барлык чараларны энергия нәтиҗәлелеге һәм энергияне сак тоту таләпләрен исәпкә алып үткәрергә.

4. «ТР ЗМР ТКХ департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә мәгълүмат бирүнең үз вакытында булуын контрольдә тотарга, анализ ясарга, иң катлаулы мәсьәләләрне Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы объектларын 2016/2017 елгы ягу чорына әзерләү эшләрен оештыру буенча координацияләү штабы утырышына чыгарырга.
5. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин